Республика Татарстан

СОВЕТ САБИНСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Татарстан Республикасы

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

САБА ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

e-mail: sab.sab@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«26» октябрь 2018 ел №35

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе муниципаль берәмлегенең Генераль планын раслау турында

Шәһәр төзелеше өлкәсендә гамәлдәге законнарны үтәү максатыннан, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше Кодексының 24 маддәсе, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 маддәсенең 4 өлеше, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының 15 маддәсенең 5 өлеше, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставының 19 маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 2006 ел, 21 ноябрь, 94 номерлы карары белән расланган “Саба муниципаль районында җәмәгать тыңлаулары турында Нигезләмә”гә яраклы рәвештә, авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарының вәкаләтләре муниципаль районның җирле әһәмияттәге сораулары булуын һәм авыл җирлекләре биләмәләрендә муниципаль район җирле үзидарә органнары тарафыннан хәл ителүен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының бәяләмәсе булуын исәпкә алып һәм уздырылган җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәләре йомгаклары буенча, Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе муниципаль берәмлегенең Генераль планын расларга (теркәлә).

2. Түбәндәге карарларны үз көчен югалткан дип санарга:

- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советының 2010нчы елның 13нче августында кабул ителгән 44нче номерлы “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе муниципаль берәмлегенең Генераль планын раслау турында”гы карары;
- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге

Советының 2015нче елның 30нчы апрелендә кабул ителгән 29нчы номерлы “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертүне раслау турында”гы карары;

- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советының 2017нче елның 29нчы ноябрендә кабул ителгән 39нчы номерлы “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертүне раслау турында”гы карары.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/saba адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырырга.

Саба шәһәр җирлеге
башлыгы урынбасары Р.М.Хәсәнов